| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.11.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3202** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районының шәһәр төзелеше советы турында

Гражданнарның гармонияле уңайлы тормыш шартларын формалаштыру буенча максатчан шәһәр төзелеше сәясәтен, төзелә һәм реконструкцияләнә торган объектларның архитектура матурлыгын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге башка законнар һәм норматив-хокукый документлар таләпләрен үтәү буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү өчен шартлар тудыру һәм җайга салу максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының шәһәр төзелеше советын төзергә.
2. Зеленодольск муниципаль районының шәһәр төзелеше советы составын расларга (1 нче кушымта).
3. Зеленодольск муниципаль районының шәһәр төзелеше советы турындагы нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 23 октябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы шәһәр төзелеше советы турында» 3240 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

ЗМР БК
2025 елның 17 ноябрендәге
3202 номерлы карары буенча
1 нче кушымта

ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ СОВЕТЫ СОСТАВЫ:

Совет җитәкчелеге

1. Хәбибуллин З.Ф. - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, совет рәисе;
2. Старостин А.В. – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, Совет рәисе урынбасары;
3. Шакиров Д.И. - «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ баш архитекторы- җитәкче урынбасары , совет секретаре;

Совет әгъзалары:

4. Сергеев П.Н. - «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе;
5. Шәмсетдинов Ф.А. - генераль план, кызыл линия, топография, геология һәм инженерлык коммуникацияләре бүлегенең баш белгече, совет секретаре. «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ;
6. Билалова И.И. - «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ проект бүлеге баш белгече;
7. Алексахина А.Ю. - «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе;
8. Ячанова Н.В. - Зеленодольск муниципаль районының баш агрономы;
9. Бауэр А.С. – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - икътисадый үсеш;
10. Зубарева Ю.В. – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – АСИҮТ;
11. Чибрикова Р.Н. - Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы;
12. Шакиров М.Г. - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы;
13. Мәхмүтов И.А.- «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе;
14. Зиннуров Р.Н. – «Зеленодольск муниципаль районының техник күзәтчелек хезмәте» МУП директоры;
15. Минһаҗев Н.Н. - «Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе;
16. Рузанова Н.А. – «Инвестиция үзәге Зелёный Дол» АУ җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы;
17. Гончаров О.В. – «Инвестиция үзәге Зелёный Дол АУ җитәкчесе урынбасары;

18. Тиняев П.И. - «Иске Казан» архитектура остаханәсе генераль директоры, җәмәгать эшлеклесе (килешү буенча).

19. Закирова Ю.А. – шәһәр төзелеше кафедрасы доценты (килешү буенча)

20. Нигъмәтуллин Д.А. - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы социаль мәсьәләләр (килешү буенча);

ЗМР БК
2025 елның 17 ноябрендәге
3202 номерлы карары буенча
2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының**
**Шәһәр төзелеше советы турындагы**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Зеленодольск муниципаль районының Шәһәр төзелеше Советы (алга таба-Совет), Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан объектлар буенча, милек формаларына һәм финанслау чыганакларына бәйсез рәвештә, архитектура һәм шәһәр төзелеше проектларын карау өчен оештырылган коллегиаль киңәшмә органы булып тора, түбәндәге максатларда:

-Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә башка законнарны һәм норматив-хокукый документларны үтәүне тормышка ашыру;

- шәһәр төзелеше дисциплинасын үтәү;

-шәһәр төзелеше документларын билгеләнгән срокларда әзерләүне тәэмин итү;

-конкурс проектларын карау ;

- төзелеш һәм төзекләндерү объектларының архитектура сыйфатын күтәрү;

- нормативларда каралган территорияләргә экологик таләпләрне үтәү;

-архитектура, шәһәр төзелеше сәнгате, тарих, мәдәният һәм ландшафт һәйкәлләрен саклау;

- җәмәгатьчелек белән фикер алышуны оештыру, штаттан тыш һәм ведомстводан тыш экспертларны җәлеп итеп, төзелеш максатлары өчен җир кишәрлекләре сайлауны, төзелеш проектларын нигезләү .

Совет тәкъдимнәре һәм бәяләмәләре шәһәр төзелеше һәм архитектура мәсьәләләре буенча район һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар эшләү һәм кабул итү өчен нигез булып тора.

Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык Министрлыгының норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

Аерым объектларның архитектура чишелешләренең иҗади сораулары Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге каршындагы архитектура Советы каравына юнәлдерелергә мөмкин.

## 2. Советның бурычлары һәм функцияләре

2.1. Советның төп бурычы булып түбәндәгеләр тора:

Зеленодольск шәһәренең һәм Зеленодольск районының торак пунктларының архитектура, шәһәр төзелеше үсеше мәсьәләләре һәм аларны хәл итү юллары, төзелешләр буенча архитектура-сәнгать ягыннан күренеш дәрәҗәсен арттыру турында фикер алышу.

2.2. Төп бурыч нигезендә Совет түбәндәге функцияләрне башкара:

-архитектура-шәһәр төзелеше үсеше, торак пунктларда төзелеш сыйфатын күтәрү проблемалары буенча тәкъдимнәр эшли;

-район торак пунктларының архитектура-сәнгать күренешен формалаштыручы күчемсез милек объектлары буенча шәһәр төзелеше таләпләренә туры килү өлешендә проект документациясен килештерү буенча рекомендацияләр эшли;

-район торак пунктларының шәһәр төзелеше документларын, шәһәр төзелеше эшчәнлеге регламентларын һәм төзекләндерү, инженерлык һәм транспорт белән тәэмин итү проектларын раслау буенча рекомендацияләр эшли;

-әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый ресурсларны рациональ файдалану, саклау һәм торгызу, архитектура, шәһәр төзелеше сәнгате, тарих, мәдәният һәм ландшафт һәйкәлләрен саклау һәм куллану буенча чаралар, шулай ук аларны саклау зоналары проектлары өчен тәкъдимнәр эшли;

-район торак пунктлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә;

-архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-техник прогресс казанышларын кертү буенча тәкъдимнәр кертә;

- расланган проектларны тормышка ашыруны, шулай ук район торак пунктларын төзү тәҗрибәсен анализлый.

## 3.Хокуклары

Совет  түбәндәгеләргә хокуклы:

- билгеләнгән тәртиптә проект һәм төзелеш оешмаларыннан, заказ бирүчеләрдән һәм төзүчеләрдән кирәкле материаллар һәм тәкъдимнәр алырга;

-Совет утырышларына планлаштырылган мәсьәләләрне карау өчен кирәк булган заказчылар, проект, төзелеш һәм башка оешмалар вәкилләрен, шәхси затларны чакырырга;

-архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларының сыйфатын күтәрү буенча тәкъдимнәр кертергә;

-архитектура һәм шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча проект һәм төзелеш оешмалары, заказчылар һәм төзүчеләр арасында каршылыкларны карарга, тиешле рекомендацияләр әзерләргә.

## 4. Совет эшен оештыру

Совет 20 кешедән тора, Совет составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Совет эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне түбәндәгеләр гамәлгә ашыралар:

- Совет рәисе - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
- Совет рәисе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, Совет рәисе урынбасары;

Советның техник эшен оештыруны Совет секретаре башкара, - «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ баш архитекторы- җитәкче урынбасары,аның вазыйфарына түбәндәгеләр керә:

- эш планнарын әзерләү һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту;
- эш планы нигезендә Совет эшчәнлеген координацияләү;
- Совет утырышларына материаллар әзерләү;
- Советта катнашучыларны чакыру, беркетмәләрне рәсмиләштерү һәм аларны Совет секретареның күрсәтмәләре нигезендә, Совет әгъзаларына һәм башка кызыксынган оешмаларга бирүне оештыру.

Совет утырышлары эш планы нигезендә, карауны таләп итә торган сораулар барлыкка килгән саен үткәрелә.

Совет утырышлары, кагыйдә буларак, кызыксынган оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый оешмалар һәм халык өчен ачык рәвештә үткәрелә.

Чираттагы утырышны үткәрү датасы, урыны һәм көн тәртибе турында Совет әгъзалары һәм чакырылган затлар һәм оешмалар, алдан планлаштырылган датага кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча, хәбәр ителергә тиеш. Совет әгъзалары Совет каравына кертелә торган материаллар белән алдан танышырга тиеш.

Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

Совет карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә, шул ук вакытта Советның һәр әгъзасы һәм чакырылган зат Совет утырышында чыгыш ясарга һәм үз фикерен язмача белдерергә хокуклы.

Совет карарлары Совет рәисе һәм Совет секретаре кул куя торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Бер атна эчендә беркетмәләрнең күчермәләре Совет әгъзаларына, кызыксынган затларга һәм оешмаларга җибәрелә.

Совет утырышлары беркетмәләре 3 ел дәвамында «ЗМР архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесендә сакланырга тиеш.

Советның эш планы секретарь тарафыннан төзелә.